РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УТЯШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
Нагорная ул., 99а с.Утяшки, 422514

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Нагорная ур., 99а Өтәшкә ав, 422514

# КАРАР

2023 елның «25» сентябре № 26

Өтәшкә авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 17 октябрендәге 25 номерлы карары белән расланган Өтәшкә авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Янгыннан ирекле саклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 04.08.2023 номерлы 445-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Өтәшкә авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Өтәшкә авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 17 октябрендәге 25 номерлы карары белән расланган Өтәшкә авыл җирлеге чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр һәм терминнар «Янгыннан ирекле саклау турында» 2011 елның 06 маендагы 100-ФЗ номерлы Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Өтәшкә авылы, Нагорная урамы, 99а йорт (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк урамы, 40а йорт (СДК бинасы).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Өтәшкә авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.А. Клопов